| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 18.11.2022 | Казан ш. | № 587-131/тэ-2022 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2021 №529-116/тэ-2021 карарына 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү һәм Казан шәһәренең Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2021 елның 30 декабрендәге 1543 номерлы боерыгы белән расланган №1.6 җылылык белән тәэмин итү системасында «Химград» технополисы территориясендә «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2021 №529-116/тэ-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә һәм 2023 елга оешма тарафыннан файдаланыла торган объектларны конкретлаштыру һәм җайга салынулы оешманың кирәкле планлаштырылган тулай табышын тәгаенләштереп,

2023 елга җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан шәһәренең Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2021 елның 30 декабрендәге 1543 номерлы боерыгы белән расланган №1.6 җылылык белән тәэмин итү системасында «Химград» технополисы территориясендә «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 №516-94/тэ-2020 карарын көчен югалткан дип тану турында» 15.12.2021 №529-116/тэ-2021 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 №648-126/тэ-2021, 17.08.2022 №130-16/тэ-2022 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән үзгәреш кертелгән 2023 елга тариф 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2021 № 529-116/тэ-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 елга төзәтмә кертү хакында» 16.12.2021 № 648-126/тэ-2022 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2021 № 529-116/тэ-2021 карарына
1 нче кушымта (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
18.11.2022 № 587-131/тэ-2022
карары редакциясендә)

Казан шәһәренең Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2021 елның 30 декабрендәге 1543 номерлы боерыгы белән расланган №1.6 җылылык белән тәэмин итү системасында «Химград» технополисы территориясендә «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2021-2025 елларга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, | Тариф төре | Чор | Җылылык чыганагының төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Казан шәһәре, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2021 елның 30 декабрендәге 1543 номерлы боерыгы белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү системасында билгеләнгән | | | | |
| 1 | «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» ҖЧҖ, түбәндәге территорияләрдә: № 1.6 җылылык белән тәэмин итү системасында «Химград» технополисы; «Изумрудный город» ТК; «Сокольники» ТК; «Оазис» ТК; «Экопарк Дубрава» ТК; «Симфония» ТК; «Дом Волшебника» ТК; «Царицинский бугор» ТК; «Взлетная полоса» ТК; «Новые Горки» ТК; «Родина» ТК; «Мой дом» ТК; «Веста» ТК; Чистай, 75 йортына карата җылылык челтәрләре | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 560,64 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 596,31 | - |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 223,62 | - |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.08.2022 кадәр | 230,81 | - |
| | | | 01.09.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 408,87 | - |
| | | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 494,48 | - |
| | | | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | 425,22 | - |
| | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 442,23 | - |
| | | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 442,23 | - |
| | | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 459,92 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге